| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Кудашевского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Кодаш авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |

18.01.2024 Кодаш авылы №36-1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының "Кодаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында" 31.01.2019 елның 47-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында" 02.11.2023 елның 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе районы прокуратурасының 16.12.2023 елның 02-08-01/174 номерлы протестын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау хакында» 31.01.2019 елның 47-1 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге Советы карарына кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Ф.М.ШАКИРОВ

Совет Кудашевского сельского поселения
Кодаш авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002501

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниөипалҗ  районы Кодаш авыл җирлеге
Советының 2024 нче елның 18 гыйнварындагы
36-1 номерлы карары белән расланды

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 31.01.2019 елның 47-1 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге советы карарына кертелә торган ҮЗГӘРЕШЛӘР:

1. 8.11 пунктында икенче җөмләне төшереп калдырырга;
2. 8.17 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;
3. 8.20 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"8.20. Муниципаль хезмәткәргә класслы чин бирү турындагы карар, әлеге статьяның 8.13 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башлыгының барлык кирәкле документлары булган класслы чин бирү турындагы тәкъдим кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.»
4. 13.5 пунктын «Федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләре белән тулыландырырга;
5. 30 бүлекне төшереп калдырырга;
6. 31 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 31.1.1 пункт белән тулыландырырга:
«31.1.1. Муниципаль хезмәт стажы Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнә »